# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге составынакерүче Юкәче торак пунктында 2024 елга үзарасалым кертү турында

№ 11

20 октябрь 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Юкәче торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Юкәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операцияда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары ( хатыны һәм 18 яшькә кадәр булган балалары), көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Юкәче торак пунктында Сабантуй милли бәйрәме һәм башка массакүләм чаралар өчен мәйданны төзекләндерү ( материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Юкәче торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту(килешү буенча эш өчен түләү);
- Юкәче торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (махсус җиһазлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Шәдче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнаржыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.В.Шрыков